| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

22.06.2020 Баулы шәһәре № 136

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Регламенты турында»гы 2005 елның 19 декабрендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр советы утырышларын югары әзерлек, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш һәм хәрби хәл чорында уздыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Регламенты турында»гы 2005 елның 19 декабрендәге 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче статьяга түбәндәге эчтәлекле 4нче пункт өстәргә:

«4. Гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәлләр режимы чорында шәһәр Советы утырышы дистанцион формада, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки әлеге пунктта билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, видеоконференцэлемтә каналларыннан файдаланып үткәрелә ала.

Совет утырышында карарлар ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сораулар бирүгә язылу, чыгыш ясауга язылу утырышта катнашучы депутатларны сораштыру юлы белән үткәрелә (кул күтәреп, Совет депутатлары тарафыннан утырыш башында билгеләнгән башка ысуллар белән).

Дистанцион рәвештә Совет утырышын үткәргәндә утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, аңа утырышта рәислек итүче имза сала. Совет утырышы беркетмәсенә утырышны үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары турында белешмә, утырыш башлану һәм тәмамлану вакыты, шулай ук әлеге регламентта каралган башка мәгълүмат кертелә.

15нче статьяның 2нче пунктындагы 2нче пунктчасында «шәһәрне үстерү планнары һәм программалары проектларын эшләүдә» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

24нче статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Советы утырышлары Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм шәһәр флагы һәм гербы урнаштырылган залларда уздырыла. Шәһәр Советы утырышлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гимннары белән ачыла һәм ябыла».

Шәһәр Советының утырышлар залында чакырылган затлар өчен махсус урыннар билгеләнә. Залда урын булмаганда, шулай ук утырышка соңга калган очракта, әлеге затлар утырыш залыннан турыдан-туры трансляция башкарылган бүлмәгә җибәрелә.»;

29нче статьяның 2нче пунктында «шәһәрне үстерү планнары һәм программалары» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе» сүзләренә алмаштырырга;

66нчы статьяның 1нче пунктында «шәһәрне үстерү планнары һәм программалары» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе» сүзләренә алмаштырырга;

киләсе эчтәлектәге 35.1 статья белән тулыландырырга:

«1. Район прокуроры, шулай ук законнар, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы белән вәкаләтле башка вазыйфаи затлар Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында шәһәр халкы һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет алар карамагына караган мәсьәләләрне караганда, Башкарма комитет хезмәткәрләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы, әгәр мондый тәкъдим депутатларның гомуми саныннан абсолют күпчелеге тарафыннан кабул ителсә.

Совет рәисе тарафыннан утырышка чакырылган вазыйфаи затка чакыру утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, утырышны үткәрү вакыты, урыны, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаи зат Совет утырышына чакыруга сәбәп булган мәсьәләне күрсәтеп җиткерелә.

5. Совет рәисе утырыш башланыр алдыннан утырышта катнашучылар Совет депутатлары булмаган затлар турында хәбәр итә.

6. Утырышка чакырылган һәм утырышта катнашкан затлар Совет эшенә катышырга (чыгыш ясарга, сүз алырга, хуплау яки канәгатьсезлек белдерергә) хокуклы түгел.

7. Совет карары буенча, чакырылган затларга әлеге регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www:pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (www:Bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы Рәисе — Р.Х. Гатиятуллин

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ